***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2021-2022 нче уку елы)
**4 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 52**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Калын сузыклардан гына торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

   а) *кишер*;

   ә) *коймак*;

   б) *чөгендер*;

   в) *китап*.

2. Саңгырау тартык авазны билгеләгез. **(2 балл)**

   а) [һ];

   ә) [й];

   б) [ж];

   в) [л].

3. Авазга караганда хәреф саны күбрәк булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

   а) *яфрак*;

   ә) *елга*;

   б) *көньяк*;

   в) *табигать*.

4. Басымы соңгы иҗеккә төшкән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

   а) *йокламагыз;*

   ә) *укымыйм*;

   б) *курчакларым*;

в) *кайчан*.

5. Омонимнардан торган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *яз, яз*;

ә) *җылы, салкын*;

б) *кечкенә, нәни*;

в) *шәһәр, кала*.

6. Парлы сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *көн(чыгыш)*;

ә) *савыт(саба)*;

б) *кара(бодай)*;

в) *сүз(тезмә)*.

7. Нокталар урынына куела торган кушымчаны билгеләгез. **(2 балл)**

*Бер тамчы*... *диңгез булмый.* (Мәкаль)

а) -*га*;

ә) -*ны*;

б) -*дан*;

в) -*да*.

8. Тәмне белдерә торган сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**

а) *кызыл*;

ә) *усал*;

ә) *түгәрәк*;

б) *ачы*.

9. Боерык фигыль кулланылган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *Алга бар – артыңа кара.*

ә) *Тамчыдан күл җыела.*

б) *Суда балык адашмас.*

в) *Сүз – чәчәк, мәкаль – букет.*

10. Җыйнак җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *Салкын кыш җитте.*

ә) *Кыш җитте.*

б) *Кояш сирәк чыга.*

в) *Бүген кар яуды.*

## II. Башыгызны эшләтегез.

Алфавитның 12, 5, 7, 15, 7, 14 нче хәрефләрен кушып әйтсәң, нинди сүз килеп чыгар? **(2 балл)**

## III. Теоретик бирем.

Нокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(10 балл)**

*Сәгать сүзендә 6* **.................**, *5* **...............** *бар; бу сүздә 2* **.............** *аваз, 3* **....................** *аваз. Сүзләрнең дөрес язылышы* **........................** *сүзлекләрдә күрсәтелә. Каты, йомшак –* **.......................** *сүзләр. Бер тамырдан ясалган сүзләр* **..............................** *сүзләр дип атала. -ны/-не –* **....................** *килеше кушымчасы.* **...................** *н и ч ә? н и ч ә н ч е? ничәү? сорауларына җавап бирә.* **....................** *н и ш л и? н и ш л ә д е? н и ш л ә р? сорауларына җавап бирә.*

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(10 балл)**

*По улице шли мальчик и девочка. А впереди них шла старушка. Было очень скользко. Старушка поскользнулась и упала.*

*Мальчик передал девочке свой портфель и бросился на помощь старушке.*

*Когда он вернулся, девочка спросила его:*

- *Это твоя бабушка?*

- *Нет, - отвечал мальчик.*

- ... (В.А. Овсеева)

2. Малай белән кызның сөйләшүен дәвам итеп, дүртәр репликадан торган диалог төзеп языгыз, үз фикерегезне белдереп, нәтиҗә ясагыз. **(10 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2021-2022 нче уку елы)
**5 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 52**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Нечкә сузыклардан гына торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *яфрак*;

ә) *телевизор*;

б) *бәйрәм*;

в) *төньяк*.

2. Яңгырау тартык авазны билгеләгез. **(2 балл)**

а) [с];

ә) [ш];

б) [ч];

в) [н].

3. Авазга караганда хәреф саны күбрәк булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *яшьлек*;

ә) *кәгазь*;

б) *төньяк*;

в) *егет*.

4. Синонимнардан торган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *баллы, татлы*;

ә) *киң, тар*;

б) *карга, карга*;

в) *озын, кыска*.

5. Ясалма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *тозлы*;

ә) *күлмәк*;

б) *түшәм*;

в) *сандык*.

6. Ялгызлык исемен билгеләгез. **(2 балл)**

а) *шәһәр*;

ә) *юлбарыс*;

б) *Әмирхан*;

в) *кура җиләге*.

7. Нокталар урынына куела торган кушымчаны билгеләгез. **(2 балл)**

*Юләр**...** акыл кирәкми.* (Мәкаль)

а) -*нең*;

ә) -*гә*;

б) -*не*;

в) -*дә*.

8. Характерны белдерә торган сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**

а) *баллы*;

ә) *зәңгәр*;

б) *зур*;

в) *куркак*.

9. Киләчәк заман хикәя фигыль кулланылган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *Ил эче – алтын бишек.*

ә) *Аз сөйлә, күп эшлә.*

б) *Тырышкан табар, ташка кадак кагар.*

в) *Һөнәр ашарга сорамый, үзе ашата.*

10. Җөмләнең иясе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Майсыз коймак табага ябыша*. (Мәкаль)

а) *майсыз*;

ә) *коймак*;

б) *табага*;

в) *ябыша*.

## II. Башыгызны эшләтегез.

Берәр хәрефен алмаштыра барып, ***бал*** сүзен ***тоз*** сүзенә әйләндерегез. **(2 балл)**

## III. Теоретик бирем.

Ноктылар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(10 балл)**

*Татар телендә 28* **......................** *аваз бар.* **...................** *авазлар иҗек ясыйлар. Нечкә сузыклардан торган сүзләргә* **.................** *кушымча ялгана. Сүзләрнең мәгънәләре* **.........................** *сүзлекләрдә күрсәтелә.* **...................** *сүзләр кушылып языла. Сан ачыклап килгән исем* **........................** *дип атала. Зат алмашлыклары берлек һәм* **....................** *санда була. Сыйфатларның*

**........................** *дәрәҗәсе -рак/-рәк кушымчалары белән күрсәтелә. Хикәя фигыльләр хәзерге,* **......................** *һәм* **.......................** *заманда кулланыла.*

### IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итегез. **(10 балл)**

*Сердце мышонка*

*Жил-был маленький Мышонок, который был несчастным, потому что всего боялся. Но больше всего он боялся попасть в лапы кошке.*

*Мышонок пришел к Волшебнику и стал его просить сделать его кошкой.*

*Волшебник пожалел мышонка и превратил его в кошку.*

*Но тогда эта кошка стала бояться собак.*

*Волшебник превратил бывшего мышонка в собаку. Но тогда он стал бояться волков. ...* (Из сказки)

2. Ни өчен әкият шулай дип аталды икән? Әкиятнең ахырын 8 җөмлә ярдәмендә язып бетерегез, үз фикерегезне белдереп, нәтиҗә ясагыз. **(10 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН

## ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ

(2021-2022 нче уку елы)

**6 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 55**

### I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Рәт гармониясенә буйсынмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *ябалак*;

ә) *болыт*;

б) *китап*;

в) *ашъяулык*.

2. Ябык иҗекләрдән генә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *сыйныфташ*;

ә) *авылдаш*;

б) *балыкчы*;

в) *бозлавык*.

3. Синонимнардан торган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *юмарт, саран*;

ә) *кара, кара*;

б) *алтын, көмеш*;

в) *батыр, тәвәккәл*.

4. ***Мәктүп*** сүзенең мәгънәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *хат*;

ә) *мәктәп*;

б) *укытучы*;

в) *белем*.

5. Тамырдаш булмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *баллы*;

ә) *балчык*;

б) *балдай*;

в) *балсыз*.

6. Парлы сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *як(таш)*;

ә) *бала(чага)*;

б) *исле(май)*;

в) *нокталы (өтер)*.

7. Төшем килешендәге исемне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *кыш*;

ә) *кышның;*

б) *кышка*;

в) *кышны*.

8. Тартымлы исем кулланылган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *Кыюлык – адәмнең канаты.*

ә) *Ашыккан бер эшне ике эшләр.*

б) *Батырлыкта матурлык.*

в) *Юләр мактаганны ярата.*

9. Предметның формасын белдерә торган сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**

а) *кайнар*;

ә) *җәйге*;

б) *түгәрәк*;

в) *оялчан*.

10. Җөмләнең иясе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Акылсыз башка алтын бүрек файда бирми.* (Мәкаль)

а) *башка*;

ә) *алтын*;

б) *бүрек*;

в) *файда*.

**II. Башыгызны эшләтегез.**

“ка” хәрефе белән башланып, “ка” хәрефенә беткән уртаклык исемнәр языгыз. **(3 балл)**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| к | | | | | к |
| к | | | | | к |
| к | | | | | к |
| к | | | | | к |
| к | | | | | к |
| к | | | | | к |

## III. Теоретик бирем.

Нокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(10 балл)**

*Татар телендә [***...***] авазы сүзнең беренче иҗегендә, [о] сузыгына охшатып, бераз иренләштерелеп әйтелә. Калын сузыклардан торган сүзгә* **........................** *кушымчалар ялгана. Язуда [***...***] һәм [в] авазлары в хәрефе белән күрсәтелә.* **....................** *җөмләләрдә тавыш башта күтәрелә, аннары төшә. Телдә яңа барлыкка килгән сүзләр* **..........................** *дип атала. Сүзлекләрдә сүзнең туры һәм* **.........................** *мәгънәсе дә күрсәтелә. Тамыр сүзгә ясагыч кушымча ялганса,* **.......................** *сүз барлыкка килә. Исемнәр берлек һәм* **......................** *санда килә. [й] авазына беткән алынмаларга тартым кушымчасы ялганганда, й хәрефе* **......** *хәрефе белән алышына. Сыйфат ияреп килгән исем* **............................** *дип атала.*

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(10 балл)**

*Собака шла по дощечке через речку. В зубах она несла кость.*

*Вдруг Собака увидела свое отражение в воде. Она подумала, что там другая собака добычу несёт. И показалось собаке, что у той собаки кость намного больше, чем у неё.*

*Собака бросила свою добычу и кинулась отнимать кость у отражения.*

*В результате Собака осталась ни с чем. И свое потеряла, и чужое отобрать не смогла.*

2. ***“Күпне өмет итсәң, аздан да коры калырсың”*** дигән фикерне дәвам итеп, 12 җөмләдән торган бәйләнешле текст языгыз. **(12 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2021-2022 нче уку елы)
**7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 55**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. [**гъ**] авазы кулланылган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *егет*;

ә) *чөгендер*;

б) *елга*;

в) *күгәрчен*.

2. Нечкә сузык авазлардан гына торган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**

ә) *Бурыч ашаганчы борыч аша.*

б) *Ала белсәң, бирә дә бел.*

в) *Бүләкнең кечкенәсе булмый.*

а) *Бүләк биргән бүләк көтә.*

3. Күчерелмә мәгънәле сүз кулланылган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *тәмле алма*;

ә) *тәмле сүз*;

б) *тәмле чәй*;

в) *тәмле аш*.

4. Фразеологик әйтелмәнең төшеп калган сүзен билгеләгез. **(2 балл)**

***Сүзне ... ташлау***

а) *җилгә*;

ә) *кешегә*;

б) *суга*;

в) *чүпкә*.

5. Кушма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *кар(сыз)*;

ә) *дус(иш)*;

б) *бал(корты)*;

в) *гөл(җимеш)*.

6. Тамырдаш булмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *саннар*;

ә) *санлы*;

б) *саный*;

в) *сандык*.

7. Тартымлы исем кулланылган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *Эшләп үлмиләр, чирләп үләләр.*

ә) *Ялкауга яңгыр иң беренче төшә.*

б) *Ялкауның көн дә башы авырта.*

в) *Эш кешене төзәтә, ялкаулык боза.*

8. Нисби сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**

а) *чибәр*;

ә) *урмандагы*;

б) *сары*;

в) *сөйкемле*.

9. Охшату-чагыштыру рәвешен билгеләгез. **(2 балл)**

а) *мамыктай*;

ә) *шактый*;

б) *юри*;

в) *күптән*.

10. Җөмләнең иясе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Ахмакка биргән киңәш далага аткан ук кебек*. (Мәкаль)

а) *ахмакка*;

ә) *киңәш*;

б) *далага*;

в) *ук*.

## II. Башыгызны эшләтегез.

“а” хәрефе белән башланып, “а” хәрефенә беткән уртаклык исемнәр языгыз. **(3 балл)**

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| а | | | | а | | |
| а | | | | а | | |
| а | | | | | а | |
| а | | | | | а | |
| а | | | | | а | |
| а | | | | | | а |

## III. Теоретик бирем.

Нокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(10 балл)**

*Татар телендә калын һәм ..................... сузыклар бар. ..................... гармониясе язуда чагылыш тапмый. Язуда авазлар ..................... белән белдерелә. .......................... мәгънә – сүзнең төп мәгънәсе. Бәйләгеч кушымчалар сүз ........................... килә. Дәрәҗә белән төрләнә торган сыйфатлар ..................... сыйфатлар була. ........................ рәвеше эш яки хәлнең үтәлү урынын һәм юнәлешен белдерә. Юклык алмашлыклары сорау алмашлыклары алдына һич һәм ..................... сүзләрен кую юлы белән ясала. Фигыльләр .............................. һәм затланышсыз була. Фигыльнең ................... төре -ма/-мә, -мый/-ми кушымчалары ялганып ясала.*

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итегез. **(10 балл)**

*Два яблока*

*Маленькая девочка принесла с улицы два яблока. Наверное, кто-то подарил.*

- *Мама, смотри, какие красивые яблоки!*

- *Да, красивые! Угостишь? – спросила мама.*

*Малышка посмотрела на яблоки. А потом откусила одного яблока. На секунду задумалась и … - надкусила второе.*

*Мама удивилась.*

2. Ни өчен бала ике алманы да кабып карады икән? Әсәрнең ахырын 12 җөмлә ярдәмендә язып бетерегез, үз фикерегезне белдереп, нәтиҗә ясагыз. **(12 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2021-2022 нче уку елы)
**8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 59**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге тартык авазларның саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Дөрес сөйләгән ялгышмый.* (Мәкаль)

а) 12;

ә) 14;

б) 15;

в) 17.

2. Җөмләдәге ябык иҗекләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Башта холык тап, аннан гыйлем.* (Мәкаль)

а) 3;

ә) 4;

б) 6;

в) 7.

3. Һөнәрчелек сүзен билгеләгез. **(2 балл)**

а) *җегет*;

ә) *мәчет;*

б) *слайсинг*;

в) *планшет*.

4. Тезмә сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *бака(яфрагы)*;

ә) *аш(су)*;

б) *бал(сыз)*;

в) *кара(бүрек)*.

5. Рәвешне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *өченче*;

ә) *икеләтә*;

б) *унлап*;

в) *бишәү*.

6. Җөмләдәге фигыльнең төркемчәсен билгеләгез. **(2 балл)**

*Начарны белмичә, яхшының кадере юк.* (Мәкаль)

а) сыйфат фигыль;

ә) хикәя фигыль;

б) хәл фигыль;

в) шарт фигыль.

7. Раслауны белдерә торган кисәкчәне билгеләгез. **(2 балл)**

а) -*мыни*;

ә) *гына*;

б) *түгел*;

в) *ләбаса.*

8. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Көн* ***саен*** *майлы ботка булмый.* (Мәкаль)

а) бәйлек;

ә) кисәкчә;

б) теркәгеч;

в) ымлык.

9. Сүзтезмәне билгеләгез. (**2 балл)**

а) *яфрак*;

ә) *үги ана яфрагы*;

б) *матур йорт*;

в) *Йорт матур*.

10. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**

*Бәла агач башыннан йөрми, кеше башыннан йөри.* (Мәкаль)

а) *бәла*;

ә) *агач*;

б) *башыннан*;

в) *кеше*.

## II. Башыгызны эшләтегез.

“че” хәрефе белән башланып, “че” хәрефенә беткән уртаклык исемнәр языгыз. **(3 балл)**

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ч | | ч | | | | | |
| ч | | | | ч | | | |
| ч | | | | ч | | | |
| ч | | | | | | | ч |
| ч | | | | | | | ч |
| ч | | | | | | | ч |

## III. Теоретик бирем.

Нокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(10 балл)**

*Иреннәрнең хәрәкәтенә карап, сузык авазлар иренләшкән һәм* **..........................** *сузыкларга бүленәләр. Күп иҗекле сүздә иҗекнең берсе башкаларга караганда көчлерәк әйтелсә, ул* **........................** *иҗек була. Капма-каршы мәгънәле сүзләр* **.............................** *дип атала. Яңа сүзләрне* **.......................** *дип атыйлар.* **.................................** *кушымчалар җөмләләрдә*

*сүзләрне бәйләү өчен кулланыла. Дәрәҗә белән төрләнә алмаган сыйфатлар* **......................** *сыйфатлар була. Сыйфат фигыль бер үк вакытта сыйфат һәм* **......................** *билгеләрен ала. Каршы куючы теркәгеч алдыннан* **....................** *куела. Ияртүле бәйләнеш нәтиҗәсендә сүзтезмә һәм* **................** *барлыкка килә. Ия һәм* **.......................** *– җөмләнең баш кисәкләре.*

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(14 балл)**

*Мальчик очень любил читать добрые сказки и верил, что там было написано. Поэтому он искал чудеса и в жизни, но не мог найти в ней ничего такого, что было бы похоже на его любимые сказки. Чувствуя некоторое разочарование от своих поисков, он спросил маму, правильно ли то, что он верит в чудеса? Или чудес в жизни не бывает?*

*«Дорогой мой, – с любовью ответила ему мама, – если ты будешь стараться вырасти добрым и хорошим мальчиком, то все сказки в твоей жизни сбудутся. Запомни, что чудес не ищут, к добрым людям они приходят сами».*

2. Сез могҗизага ышанасызмы? Малайның әнисе хаклымы? Шул хактагы фикерләрегезне 12 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. **(12 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2021-2022 нче уку елы)
**9 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 60**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Ирен ассимиляциясе чагылыш тапкан сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *урамнан;*

ә) *төнбоек;*

б) *көнгерә;*

в) *балсыз.*

2. Фразеологик әйтелмәнең мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**

***Бергә бишне кушып сөйләү***

а) чын дөресен сөйләү;

ә) бер вакыйганы да төшереп калдырыйча сөйләү;

б) арттырып сөйләү;

в) аңлаешлы итеп сөйләү.

3. Ясалма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *күлмәк*;

ә) *балта*;

б) *сандык*;

в) *бушлай*.

4. Билгесезлек алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

а) *нинди*;

ә) *кайсыдыр*;

б) *һичкем*;

в) *һәркем*.

5. Затланышсыз фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**

а) хикәя фигыль;

ә) сыйфат фигыль;

б) шарт фигыль;

в) боерык фигыль.

6. Юнәлеш килешен таләп итүче бәйлекне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *таба*;

ә) *кебек*;

б) *соң*;

в) *тыш*.

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеге дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Тирән **күлдә** балык та күбрәк.* (Мәкаль)

а) урын хәле;

ә) тәмамлык;

б) аергыч;

в) хәбәр.

8. Җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Яхшы суны ерак түкмиләр.* (Мәкаль)

а) ким җөмлә;

ә) ике составлы җөмлә;

б) бер составлы исем җөмлә;

в) бер составлы фигыль җөмлә.

9. Җөмләнең хәбәрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Суга батучы саламга да ябыша.* (Мәкаль)

а) *суга*;

ә) *батучы*;

б) *саламга*;

в) *ябыша*.

10. Кушма җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *Елга, күпме боргаланса да, диңгезгә төшәр.* (Мәкаль)

ә) *Яхшыга да бер кояш, яманга да бер кояш.* (Мәкаль)

б) *Вакыт акчадан кадерлерәк.* (Мәкаль)

в) *Көндезге эш кичке эштән көләр.* (Мәкаль)

## II. Башыгызны эшләтегез.

“ә” хәрефе белән башланып, “ә” хәрефенә беткән уртаклык исемнәр языгыз. **(3 балл)**

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| ә | | | ә | | | |
| ә | | | ә | | | |
| ә | | | | ә | | |
| ә | | | | ә | | |
| ә | | | | | ә | |
| ә | | | | | | ә |

## III. Теоретик бирем.

Нокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(10 балл)**

*Сузык авазлар* **................** *ясыйлар. [къ], [гъ] авазлары* **.................** *теленнән кергән сүзләрдә кулланылмый.* **...........................** *– бертөрле әйтелеп, төрле мәгънә белдерә торган сүзләр. Кулланылышы чикләнгән сүзләргә диалекталь һәм* **..........................** *сүзләре керә.* **...........................** *сүзләр ике сүз кушылып ясала.* **..........................** *алмашлыгы -ныкы/-неке кушымчасы ялганып ясала. Аваз ияртеменнән -ла/-лә кушымчасы ярдәмендә* **....................** *ясала. Ия төзелеше ягыннан гади һәм* **...................** *була. Аныклагыч ияреп килгән сүз* **...........................** *дип атала. Теркәгечле тезмә кушма җөмлә компонентлары арасына* **...........................** *куела.*

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итегез. **(12 балл)**

*Спор ветра с солнцем*

*Однажды сердитый северный Ветер и Солнце затеяли спор, кто из них сильнее. Долго они спорили и решили испробовать свою силу на одном путешественнике.*

*Ветер сказал: «Я сейчас вмиг сорву с него плащ!» И начал дуть. Он дул очень сильно и долго. Но человек только плотнее закутывался в свой плащ.*

*Тогда Солнце начало пригревать путника. Он сначала опустил воротник, потом развязал пояс, а потом снял плащ и понёс его на руке. Солнце сказало Ветру: «Видишь: добром, лаской можно добиться гораздо большего, чем насилием».*

2. Сез Кояш белән килешәсезме? Шул хактагы фикерләрегезне 15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. **(15 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2021-2022 нче уку елы)
**10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 62**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Басымы соңгы иҗеккә төшкән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *җырламый*;

ә) *кайтканнар*;

б) *йоклаганчы*;

в) *бармагыз*.

2. Фразеологик әйтелмәнең төшеп калган сүзен билгеләгез. **(2 балл)**

***Саташкан ... кебек***

а) *күке*;

ә) *эт;*

б) *кеше*;

в) *карга*.

3. Ясалма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *кызым*;

ә) *кып-кызыл;*

б) *кызык*;

в) *кызучан*.

4. Җөмләдәге саннарның төркемчәсен билгеләгез. **(2 балл)**

*Йөз явызлыкны бер дөреслек җиңә.* (Мәкаль)

а) микъдар;

ә) тәртип;

б) чама;

в) җыю.

5. Җөмләдәге фигыльнең төркемчәсен билгеләгез. **(2 балл)**

*Бер яхшы сүз мең күңелнең җәрәхәтен төзәтер.* (Мәкаль)

а) исем фигыль;

ә) сыйфат фигыль;

б) хәл фигыль;

в) хикәя фигыль.

6. Ымлыкны билгеләгез. **(2 балл)**

а) *ләкин*;

ә) *ләбаса;*

б) *уф*;

в) *бәлки*.

7. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәгенә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

***Табылган*** *табышмак биң җиңел күренә.* (Мәкаль)

а) аергыч;

ә) хәбәр;

б) тәмамлык;

в) хәл.

8. Җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Былтыр кысканга быел кычкырмыйлар.* (Мәкаль)

а) ким җөмлә;

ә) ике составлы җөмлә;

б) бер составлы фигыль җөмлә;

в) бер составлы исем җөмлә.

9. Җөмләдәге иярчен компонентның төзелеше һәм мәгънә ягыннан төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Кеше биргән бүләкне кешегә бүләк итмә.* (Мәкаль)

а) синтетик аергыч җөмлә;

ә) синтетик тәмамлык җөмлә;

б) аналитик тәмамлык җөмлә;

в) синтетик урын җөмлә.

10. Җөмләдәге компонент арасында куела торган тыныш билгесе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Нәфесне нәрсәгә өйрәтсәң* ***(...)*** *шуны куар.* (Мәкаль)

а) сызык;

ә) ике нокта;

б) нокталы өтер;

в) өтер.

## II. Башыгызны эшләтегез.

Т*аш* сүзе белән кушылып ясалган уртаклык исемнәр языгыз. **(3 балл)**

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| т | а | ш | | | | | | |
| т | а | ш | | | | | | |
| т | а | ш | | | | | | |
| т | а | ш | | | | | | |
| т | а | ш | | | | | | |
| т | а | ш | | | | | | |

## III. Теоретик бирем.

Нокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(10 балл)**

*[й] – тел* **..................** *тартыгы. Кулланылыштан төшеп калган сүзләрне* **........................** *сүзләр дип атыйлар. Бәйләгеч кушымчалар сүз* **.......................** *килә.* **..........................** *саны предметларның яисә затларның тигез өлешләргә бүленүен белдерә. Саннар исемнәргә һәм* **........................** *ияреп килә. Туры сүз тәртибендә аергыч аерылмыш* **......................** *урнаша. Максат хәле* **.....................** *заманга, ә сәбәп хәле* **........................** *заманга карый. Баш кисәкләрдән* **....................** *генә булган җөмлә бер составлы исем җөмлә дип атала. Иярчен* **.......................** *җөмлә баш җөмләнең вакыт хәле урынында килә.*

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(14 балл)**

*Всё в твоих руках*

*В одном городе жил великий мудрец. Люди издалека приходили к нему за советом.*

*Но был в городе человек, завидующий его славе. Пришёл он на луг, поймал бабочку, посадил её между сомкнутых ладоней и подумал:*

- *Пойду я к мудрецу и спрошу у него: скажи, о мудрейший, какая бабочка у меня в руках – живая или мёртвая? Если он скажет мёртвая, я открою ладони, бабочка улетит. Если он скажет живая, я сомкну ладони, и бабочка умрет. Вот тогда все поймут, кто из нас умнее.*

2. Ни өчен әсәр шулай дип аталган? Әсәрнең ахырын язып бетерегез, үз фикерегезне белдереп, нәтиҗә ясагыз, 15 җөмлә ярдәмендә бәйләнешле текст төзегез. **(15 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2021-2022 нче уку елы)
**11 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 62**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Борын ассимиляциясе чагылыш тапкан сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *тиеннәр;*

ә) *унбиш;*

б) *әнкәй;*

в) *китаплар.*

2. Диалекталь сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *угры;*

ә) *ясак;*

б) *флешмоб;*

в) *инәй.*

3. Кыскартылма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *күкчәчәк*;

ә) *өс-баш*;

б) *телестудия*;

в) *каен җиләге*.

4. Нисби сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**

а) *соры*;

ә) *фәнни*;

б) *тирән*;

в) *эшчән*.

5. Затланышлы фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**

а) хәл фигыль;

ә) сыйфат фигыль;

б) шарт фигыль;

в) инфинитив.

6. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеге дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Яхшы **кешенең** эче белән тышы бердәй була.* (Мәкаль)

а) аергыч;

ә) тәмамлык;

б) хәл;

в) ия.

7. Җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Без капчыкта ятмый.* (Мәкаль)

а) раслау, ике составлы, ким җөмлә;

ә) инкяр, ике составлы, тулы җөмлә;

б) инкяр, бер составлы, ким җөмлә;

в) раслау, ике составлы, тулы җөмлә.

8. Җөмләдәге иярчен компонентның төзелеше һәм мәгънә ягыннан төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Җир кемнеке, икмәге шуныкы.* (Мәкаль)

а) аналитик хәбәр җөмлә;

ә) аналитик тәмамлык җөмлә;

б) аналитик аергыч җөмлә;

в) аналитик ия җөмлә.

9. Җөмләдәге иярчен компонентның төзелеше һәм мәгънә ягыннан төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Кош кунмаган агач юк.* (Мәкаль)

а) синтетик тәмамлык җөмлә;

ә) синтетик урын җөмлә;

б) синтетик аергыч җөмлә;

в) аналитик аергыч җөмлә.

10. Җөмләдәге компонентлар санын билгеләгез. **(2 балл)**

*Очы юк эш – төбе юк чүмеч.* (Мәкаль)

а) 2;

ә) 3;

б) 4;

в) 5.

## II. Башыгызны эшләтегез.

Б*аш* сүзе белән кушылып ясалган уртаклык исемнәр языгыз. **(3 балл)**

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| б | а | ш | | | | |
| б | а | ш | | | | |
| б | а | ш | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| б | а | ш | | | | | | | | |
| б | а | ш | | | | | | | | |
| б | а | ш | | | | | | | | |

### III. Теоретик бирем.

Нокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(10 балл)**

*Тартык авазга тәмамланган иҗек* **..............** *иҗек дип атала. Язылышлары төрле, әйтелешләре бертөрле булган сүзләр* **...................** *дип атала. Мин, без –* **.......................**; *син, сез – тыңлаучылар.* **...............** *саны предметның исәбен якынча белдерә.* **..........................** *юклык төре -маска/-мәскә кушымчалары ярдәмендә ясала. Кисәкчәләр сызыкча, аерым һәм* **...................** *языла ала. Эш-хәлнең, хәрәкәтнең максатын белдереп, җөмләнең фигыльне ачыклап килә торган иярчен кисәге* **...................** *хәле дип атала. Сорау җөмлә сорау* **........................** *белән белдерелә. Иярчен җөмлә төзелеше ягыннан* **...................** *һәм* **......................** *була.*

### IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итегез. **(14 балл)**

*А почему ты?*

*Маленький Мишутка спросил своего отца Медведя:*

- *Скажи мне, волк самый храбрый?*

- *Он очень храбрый, намного храбрее, чем я, - ответил медведь.*

- *А тигр сильный? – не унимался Мишутка.*

- *Невероятно сильный, я с ним и близко сравниться не смогу.*

- *А рысь ловкая?*

- *Она настолько ловка, что лист не шелохнётся, когда она охотиться за добычей.*

- *Говорят, лиса очень умная.*

- *Да, сынок, правильно говорят. Она действительно умна.*

- *Так почему, папа, ты глава леса, а не тигр, волк или умная лиса? – в недоумении спросил Мишутка.* (Андрей Мэрко)

2. Әтисе улына ни дип җавап бирде икән? Әсәрнең ахырын язып бетерегез, үз фикерегезне белдереп, нәтиҗә ясагыз, 15 җөмлә ярдәмендә бәйләнешле текст төзегез. **(15 балл)**